| | | |
|---|---|---|
| | адресы мөрәҗәгать итүче белән элемтә өчен.<br>Гавами сервитут билгеләү кирәклеген нигезләүдә үтенечнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:<br>1) федераль, региональ яки җирле әһәмияттәге объектны урнаштыруны күздә тоткан территориаль планлаштыру документын раслау турында карар реквизитлары, гавами сервитутны билгеләү турында үтенечнамә бирелгән очракта, федераль, региональ яки җирле әһәмияттәге инженерлык корылмаларын урнаштыруны күздә тоткан, территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү өчен инженерлык эзләнүләрен үткәрү максатларында, аларны төзү, реконструкцияләү өчен инженерлык эзләнүләрен үткәрү максатларында, шулай ук мондый инженерлык корылмаларын төзү яки реконструкцияләү максатларында, әгәр мондый инженерлык корылмалары шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә территориаль планлаштыру документларында чагылырга тиеш булса;<br>2) инженерлык корылмасын, автомобиль юлын, тимер юлларны урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру проектын раслау турында карар реквизитлары, инженерлык корылмасын төзү, реконструкцияләү максатларында гавами сервитутны билгеләү турында, күрсәтелгән автомобиль юлы, тимер юлларның гомуми файдаланудагы тимер юллары, автомобиль юллары белән кисешкән урыннарын урнаштыру, автомобиль юлының башка автомобиль | РФ Җир кодексының 39.41ст. 2п. |

Процедураның нәтиҗәсе: сайтта урнаштырылган документлар белән Үтенечнамәләр һәм Палатаның гавами сервитутын билгеләү мөмкинлеге турында бастырылган хәбәр.

3.6.2. Гавами сервитут соралган җир кишәрлекләренә хокукка ия булучылар гавами сервитут билгеләү өчен вәкаләтле органга тапшыралар җир кишәрлекләренә аларның хокукларын (хокукларны чикләүне) исәпкә алу турында гариза, бу хокукларны (хокукларны чикләүне) раслаучы документларның күчермәләрен кушып.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар хәбәр басылып чыккан көннән соң 30 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәләре: җир кишәрлекләренә хокукларны (хокукларны чикләүне) исәпкә алу турында гариза, бу хокукларны (хокукларны чикләүне) раслаучы документларның күчермәләрен кушып.

3.7. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү һәм бирү

3.7.1. Палата белгече башкара:

гаризага кушып бирелә торган документларның булуын тикшерү;

гавами сервитут өчен түләүне исәпләү;

гавами сервитутны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү;

Палата рәисе белән килештерү;

документны Палата җитәкчесенә раслауга җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Россия Федерациясе Җир кодексының 39.43 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасы белән билгеләнгән 30 көнлек срок тәмамланганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: раслауга юнәлдерелгән документ.

3.7.2. Палата җитәкчесе документка имза куя, теркәү өчен Палатага җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган документ яки баш тарту турында хат теркәлүгә җибәрелгән.

3.7.3. Палата белгече:

документны терки;

"Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында гавами сервитут урнаштыру турында карар урнаштыра;

җирлек, шәһәр округы (муниципаль район, гавами сервитут билгеләнгән җир кишәрлекләре һәм (яки) җирләр җирлекара территориядә урнашкан очракта) уставының муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны (аңа кушымталардан тыш) бастырып чыгаруны тәэмин итә, күрсәтелгән карар кабул ителгән җир кишәрлекләренең урнашу урыны буенча;

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.42 статьясындагы 1 яки 8 пункты нигезендә кергән, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәдә һәм җир кишәрлекләренә хокукларны (хокукларның йөкләмәләрен) исәпкә алу турындагы гаризаларда күрсәтелгән почта адреслары буенча тапшыру турында хәбәрнамә белән хокуклар турындагы мәгълүматлар һәм гавами сервитут билгеләү турында карар

